**МЕЖРЕГИОНАЛЬНАЯ ОЛИМПИАДА ШКОЛЬНИКОВ «ЮНИОР»**
**ПО ТАТАРСКОМУ ЯЗЫКУ**
**ЗАКЛЮЧИТЕЛЬНЫЙ ЭТАП**
**2022-2023 учебный год**
**5 КЛАСС**

## Критерии оценивания

**Таблица ответов**

| | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | | X | X | | | | X | | | X | X |
| **2** | | | | X | | | | | | | |
| **3** | X | | | | | | | | X | | |
| **4** | | | | | X | X | | X | | | |
| | ***задания по 4 балла*** | | | | | | | | | | |

1. Җөмләдәге калын сузык авазларның санын билгеләгез.
*«Һөнәр ашарга сорамый, үзе ашата»*. (Мәкаль) (4 балл)

1) 4
2) 8
**3) 9**
4) 5

2. Кайсы сүздә басым дөрес куелмаган? (4 балл)
**1) әммá**
2) мәгълүмáт
3) кагыйдә́
4) туганнардá

3. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да нокталар урынына һ хәрефе языла? (4 балл)
**1) ....әркем, ....әрвакыт**
2) мә...әббәт, ....ичкем
3) и...тимал, ...әзинә
4) ...рмәт, ...исапчы

4. *Саубуллашу* сүзенең тамырларын күрсәтегез: (4 балл)
1) сау
**2) сау бул**
3) саубуллаш
4) саубуллашу

5. Җөмләдә аерып бирелгән исемнәрнең килешен дөрес билгеләгез: “***Сабанда*** *сайрашмасаң,* ***ындырда*** *ыңгырашырсың” (Мәкаль)* (4 балл)
1) чыгыш килешендә
2) төшем килешендә
3) юнәлеш килешендә
**4) урын-вакыт килешендә**

6. Безнең тәрәзә арасына бер кош оя ясаган җөмләсендә БЕЗНЕҢ сүзе кайсы сүз төркеменә карый? (4 балл)
1) исем
2) сыйфат
3) кисәкчә
**4) алмашлык**

7. Кайсы рәттә җөмләнең тиңдәш кисәкләрен аера торган өтерләр бар? (4 балл)
**1) Кибеттә кызыл, яшел, зәңгәр төсле күлмәкләр бар.**
2) Алинә, кил әле яныма.
3) Без, бишенче сыйныф укучылары, бүген әдәбият дәресендә булдык.
4) Мин, әлбәттә, яхшы укырга телим.

8. *Табарга* сүзенең антонимын күрсәтегез. (4 балл)
1) эзләргә
2) тикшерергә
3) шатланырга
**4) югалтырга**

9. Әдәби геройлар нинди ике төркемгә бүленә? (4 балл)
1) әйбәтләр һәм начарлар
2) батырлар һәм куркаклар
**3) төп һәм ярдәмче**
4) олылар һәм яшьләр

10. Гаяз Исхакый – (4 балл)
**1) язучы, драматург**
2) язучы, рәссам
3) язучы, сәүдәгәр
4) язучы, биюче

11. М.Җәлилнең «Сандугач һәм чишмә» балладасындагы төп геройларны атагыз. (4 балл)
**1) Сандугач, чишмә, солдат**
2) Кояш, сандугач, солдат
3) Чишмә, күбәләк, кояш
4) Дөрес җавап юк

12. Әсәрләрнең авторларын языгыз. (8 балл)
“Шүрәле” Габдулла Тукай
“Патша һәм карт” Каюм Насыйри
“Чуар тавык” Абдулла Алиш
“Кәҗүл читек” Гаяз Исхакый

13. Әсәрләрнең жанрларын языгыз. (8 балл)
“Шүрәле” әкият
“Патша һәм карт” әкият
“Чуар тавык” әкият
“Кәҗүл читек” хикәя

14. Бирелгән өзекне дәвам итегез, авторын, жанрын языгыз. (5 балл)
“Җәй көне. Эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.
Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм, дип уйлагач”
Габдулла Тукайның “Су анасы” поэмасы

15. Бу өзек кайсы әсәрдән алынган? Аның исемен, авторын, жанрын языгыз. (5 балл)

“Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган. Ул үзе, сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. «Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим», – дип башлап китә торган булган ул сүзен.”

Абдулла Алишның “Сертотмас үрдәк” әкияте.

16. 15 биремдә бирелгән әсәрнең төп фикерен языгыз. Әсәрдә нинди тема яктырыла? (10 балл)
Абдулла Алишның “Сертотмас үрдәк” әкиятендә башкаларга серләр сөйләргә кирәкми дип әйтелә. Дөрес сүзләр сайларга һәм мөһим мәгълүматны сөйләргә мөмкин кешеләрне җентекләп сайларга кирәк.

17. “Минем туган ягым” дигән тема буенча 5 җөмләдән ким булмаган инша языгыз. (20 балл)